МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.06.2021 г.Казань № 416

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 1 июлендә 7786 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән зыянны каплау өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 июлендәге 602 номерлы боерыгы белән расланган Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә ките-релгән зыянны каплау өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәла-мәтлеккә китерелгән зыянны каплау өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең админис-тратив регламентын раслау турында» 2012 елның 26 июлендәге 602 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 18.11.2015 №850, 07.06.2016 №317, 08.06.2017 №350, 15.11.2017 №802, 19.02.2018 №138, 15.05.2018 №368, 18.09.2018 №886, 20.06.2019 №486, 03.09.2019 №664, 12.11.2019 №988, 10.02.2020 №84, 13.07.2020 №500,

13.10.2020 №720 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәреш-ләре белән) белән расланган Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән зыянны каплау өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регла-ментына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 11.06.2021 № 416 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән зыянны каплау өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 июлендәге 602 номерлы боерыгы белән расланган Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән зыянны каплау өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан Үзәкнең Татарстан Респуб-ликасы муниципаль районы һәм шәһәр округындагы бүлекчәсендә (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасында даими яшәү урыны буенча күрсәтелә.»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Компенсация билгеләү турында гариза (почта адресын яки мөрә-җәгать итүче тарафыннан федераль законнар нигезендә социаль түләүләрне алу өчен кредит оешмасында ачылган счет реквизитларын, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турындагы белешмәләрне күрсәтеп) (гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән). Опекун (попечитель), мөрәҗәгать итүчегә социаль түләүләрне күчерү өчен, кредит оешмасында опекун (попечитель) тарафыннан ачылган номинал счет реквизит-ларын тапшыра;

2) социаль ярдәм чараларына хокук бирә торган таныклык күчермәсе.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 1, 2, 3 пунктчараларында күрсәтел-гән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

ведомствоара эксперт советыннан яисә хәрби медицина комиссиясеннән инвалидлыкның радиация тәэсире белән яисә Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерү эшләренә («Маяк» ЖБ авария, аеруча куркыныч бүлекчәләрендәге эш-ләрдә турыдан-туры катнашу нәтиҗәсенә) бәйле булуы турында бәяләмә күчермәсе.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 4, 6 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә тәрбиясендә хезмәткә сәләтсез затлар булуын раслый торган документларны (18 яшен тутырмаган балалардан тыш, тәрбиядә тору факты турында суд карары, бала тууын дәүләт теркәвенә алу турында чит ил дәүләтенең компетентлы органнарыннан бирелгән таныклык күчермәс һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе, уллыкка (кызлыкка) алу турында

гражданлык хәле актларын теркәү органнары яки Россия Федера-циясенең консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән таныклыкларның күчермәләре) тапшыра.»;

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән граж-даннар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

а) ведомствоара эксперт советыннан яисә хәрби медицина комиссия-сеннән тукландыручының вафат булуының (һәлак булуының) Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләренә бәйле булуы турында бәяләмә күчермәсе;

б) тәрбиядә эшкә сәләтсез затлар булуын раслый торган документлар (хезмәт кенәгәсенең тиешенчә таныкланган күчермәсе һәм (яки) хезмәткәрнең хезмәт эшчәнлеге турында (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлар өчен) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1] статьясында билгеләнгән тәртип-тә алынган белешмәләр, 18 яше тулмаган балалардан тыш, тәрбиядә тору факты турында суд карары);

в) ата-ананың берсе, ире (хатыны) яисә гаиләнең башка әгъзасының, яшенә һәм хезмәткә сәләтле булу-булмавына бәйсез рәвештә, балаларны, ир туганнарын, кыз туганнарын, вафат булган тукландыручының 14 яшенә җит-мәгән, яисә күрсәтелгән яшенә җитсә дә, медик-социаль экспертиза дәүләт хезмәте учреждениесенең яисә сәламәтлек саклау буенча дәүләт системасының дәвалау-профилактикалау учреждениеләре бәяләмәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча ятлар каравына мохтаҗ дип танылган оныкларын караву һәм эшләмәве турында белешмә.

Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе гражданины паспортын күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очрак-ларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган һәм мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклый торган документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законна-рында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тара-фыннан кәгазьдә яисә почта юлламасы белән тапшырыла (җибәрелә) ала.

Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файда-ланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

«Хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәгечә алынырга мөмкин:

тиешле рәвештә таныкланган кәгазь документ яисә гади электрон имза (эш бирүчедә андый булган очракта) белән имзаланган электрон документ формасында соңгы эш урыны буенча эш бирүчедән (әлеге эш бирүчедә эшләгән чор өчен);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә тиешенчә расланган кәгазь документ рәвешендә;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан тиешле рәвештә расланган кәгазь документ рәвешендә яисә гади электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында;

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан файдаланып, гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында (вәкаләтле органнарда);

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында (вәкаләтле органнарда);

туендыручы затның вафаты турында (вәкаләтле органнардан);

вафат булган туендыручының уртача айлык хезмәт хакы турында белешмә (вәкаләтле органнарда);

хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр (2020 елның 1 гыйнварыннан башланган чорга) (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

белем бирү йортыннан вафат булган тукландыручының ай саен түләнә торган акчалата сумманы алу хокукына ия гаилә әгъзасының әлеге уку йортын-да көндезге формада белем алуы турында белешмә (вәкаләтле органнардан);

балага опека (попечитель) билгеләнүе турында (вәкаләтле органнардан);

пенсия алу факты турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча теркәлгән гражданнар турында (Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федера-циясе Пенсия фондында);

инвалидлык билгеләү факты турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Мөрәҗәгать итүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документ-ларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗә-гать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокук-лы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә

ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тап-шыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федера-циясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны»;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон формада вәкаләтле органнардан түбәндәгеләр турында белешмәләр ала:

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында;

туендыручының үлеме турында»;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында, вәкаләтле органга;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында, вәкаләтле органга;

туендыручының үлеме турында, вәкаләтле органга;

вафат булган туендыручының уртача айлык хезмәт хакы турында белешмә, вәкаләтле органга;

хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр (2020 елның 1 гыйнварыннан башланган чорга) (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

белем бирү йортыннан вафат булган тукландыручының ай саен түләнә торган акчалата сумманы алу хокукына ия гаилә әгъзасының әлеге уку йортын-да көндезге формада белем алуы турында белешмә, вәкаләтле органга;

балага опека (попечитель) билгеләнүе турында, вәкаләтле органга;

мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча теркәлгән гражданнар турында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарына;

Россия Федерациясе Пенсия фондына – дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка пенсия билгеләү турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондына –хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

инвалидлык билгеләү факты турында, Россия Федерациясе Пенсия фондына.

3.4.1 һәм 3.4.2 пунктларда билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Үзәк бүлекчәсе белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки;

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерә;

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалау өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен юлланган компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәт-кәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозыл-ганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.».